МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

5.11.2019 г.Казань № 920

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 28 ноябрендә 5886 номеры белән теркәлде

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законны үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р.Фәйзуллинга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы белән расланды

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчеләр булып 18 яшенә җитмәгән биш һәм аннан да күбрәк балалы Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында гариза бирүченең даими яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.

1.3.2. Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәк бүлегенең эш сәгатьләрендә, алар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Үзәк) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. мәгълүмат стендларында

урнаштырыла торган, дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, №47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибе (алга таба – 625 номерлы тәртип) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы pravo.tatarstan.ru; кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибе (алга таба – 803 номерлы тәртип) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы pravo.tatarstan.ru).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәтеннән файдалану турында мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | 18 яше тулмаган биш һәм аннан да күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү (алга таба – айлык пособие) | 803 номерлы тәртипнең 1 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 803 номерлы тәртипнең 5 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Ай саен түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | 803 номерлы тәртипнең 7 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып | Айлык пособиене билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар айлык пособиене билгеләү турында гариза кирәкле барлык документлары белән теркәлгән көннән башлап 12 эш көне эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Карар бирү айлык пособиене билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар кабул ителгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | 803 номерлы тәртипнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча айлык пособиене билгеләү турында гариза.<br>625 номерлы тәртип нигезендә гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләгәндә гариза бирүченең һәм аның гаилә составында исәпкә алына торган затларның керемнәрен раслый торган документлар<br>а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында;<br>б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы;<br>в) дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация;<br>г) эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы;<br>д) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьянлык (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр;<br>е) отставкага киткән судьяларны ай саен гомер буе тәэмин итү; | 803 номерлы тәртипнең 5 пункты 625 номерлы тәртипнең 1.2; 2.1; 2.2 пунктчалары |

ж) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән өстәмә түләүләр һәм азык-төлек тәэминаты;

з) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү;

и) социаль түләүләр:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм;

хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм 3 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесе бәяләмәсе буенча аларның балалары читләр каравына мохтаҗ булса, ир белән хатынның хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә

мәҗбүр булган чорда айлык пособие;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре;

медицина күрсәткечләре буенча академия ялында булган чорда студентларга, аспирантларга һәм докторантларга бирелә торган компенсация түләүләре;

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре балаларына айлык пособие;

хәрби хезмәткәр яки хәрби җыеннарга чакыртылган гражданин үзенең хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) йә хәрби травма алу нәтиҗәсендә вафат булган очракта гаиләнең һәр гаилә әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация;

к) милек хокукында гаиләнеке (аның гаилә әгъзаларыныкы), җан башына уртача керемне исәпләгәндә 625 номерлы тәртип нигезендә гариза бирүченең гаилә составында исәпкә алына торган затларныкы булган мөлкәттән алынган керемнәр, андыйларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гараждарны), транспорт һәм бүтән механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән алынган керемнәр;

шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җиләк-җимешләрне һәм продукцияне сатудан кергән керемнәр;

л) керемнәрнең башка төрләре, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарыннан, җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан эштән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең, шул исәптән инвалидлык яисә яше җитүгә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу сәбәпле элеккеге, эштән киткән хезмәткәрләренә матди ярдәм;

Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында законнары нигезендә алына торган авторлык бүләкләүләре, шул исәптән мирас итеп алуның авторлык шартнамәләре буенча;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма мөлкәте белән идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;

гариза бирүченең гаилә әгъзалары (625 номерлы тәртип нигезендә гаиләнең җан башына исәпләнәндә уртача керемен исәпләгәндә гариза бирүченең гаилә составында исәпкә алына торган затлар) тарафыннан алына торган алиментлар;

банк кертемнәре буенча процентлар;

мирас ителгән һәм бүләк ителгән акчалар.

3. Бала (балалар) тууы турында таныклык күчермәсе – баланың (балаларның) тууын дәүләт теркәвенә алу Татарстан Республикасыннан читтә гамәлгә ашырылган очракта;

4. Өйләнешүне теркәү турында таныклык күчермәсе – өйләнешү Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алынган очракта;

5. Ышаныч кәгазе – айлык пособие билгеләү өчен гариза гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат яки гариза бирүченең

законлы вәкиле тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә тапшырылган очракта;

6. Гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан (625 номерлы тәртип нигезендә гаиләнең җан башына исәпләнәндә уртача керемен исәпләгәндә гариза бирүченең гаилә составында исәпкә алына торган затлардан) яки аларның законлы вәкилләреннән документ(лар) (ирекле формада), түбәндәге(ләр)не раслый торган:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү ризалыгы булуны;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр нотариус тарафыннан яисә документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) тарафыннан таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза

| | | |
|---|---|---|
| | бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>бала(лар)ның тууы Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта – балаларның туунын дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – өйләнешү Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта (вәкаләтле органнарда);<br>ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкара торган опекуннарга (попечительләргә) түләнә торган бүләк күләме турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) зат тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле | 803 номерлы тәртипнең 6 пункты 625 номерлы тәртипнең 2.1; 2.2 пунктчалары |

| | | |
|---|---|---|
| | бүләкләүләрнең суммасы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>социаль түләү күләме турында мәгълүматлар:<br>Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Эчке эшләр министрлыгында);<br>Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Оборона министрлыгында);<br>пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләр, компенсация түләүләре һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган матди тәэминатлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>эшсезлек буенча пособиеләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);<br>эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);<br>һөнәри белем алган һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган чорда гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);<br>җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);<br>вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | органнарында);<br>эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарында);<br>йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарында);<br>йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарында);<br>яшь ярымлык яшенә җиткәнче бала карау буенча ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарында);<br>чакырылыш буенча хәрби хезмәт үти торган хәрби хезмәткәрнең баласына ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарында);<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен компенсация (социаль яклау органнарында);<br>читләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими рәвештә мохтаҗ 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү (социаль яклау органнарында);<br>берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә яшь ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарында);<br>гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә | |

| | | |
|---|---|---|
| | субсидияләр (шул исәптән субсидияләр-ташламалар) (социаль яклау органнарында);<br>торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсацияләр (социаль яклау органнарында).<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары; җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләргә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документларның (документларның күчермәләренең) тапшырылуы.<br>4. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләренең күрсәтелмәве.<br>5. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә дәүләт хезмәтеннән файдалануга хокукның булмавын ачыклау аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | 803 номерлы тәртипнең 8 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указының 1. п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда | Россия Федерациясе Президентының |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы; | 880 номерлы тәртипнең 2.4 пункты;<br>РФ Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында | гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | - Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының (625 номерлы тәртип нигезендә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә аның гаилә составында исәпкә алына торган затларның) яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документлар 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон | 803 номерлы тәртипнең 14, 15 пунктлары; 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | имза белән таныкланган булырга тиеш. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте нәтиҗәсен почта буенча җибәрү.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә

Гариза бирүче шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, шул исәптән, техник мөмкинлек булганда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән ысулның нинди булуына карап, гариза бирүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен зарури булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

Гариза бирүче айлык пособие билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документлар күчермәләрен теркәп тапшыра.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлеге хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы

Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры (гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гариза почтадан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгәндә, – гаризаны теркәү датасы һәм беркетелгән керү номеры турында хәбәр җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү турында язу яисә гариза бирүчегә кайтарып бирелгән документлар, гариза бирүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) хәбәр итү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, вәкаләтле органнардан;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында – өйләнешү Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта, вәкаләтле органнардан;

халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән – эшсезлек буенча пособие күләме турында;

эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

һөнәри белем алган һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган чорда гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында түләнә торган түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләнә торган түләүләр күләме турында – халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләреннән;

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә айлык матди тәэминатлар һәм күләмнәре турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

социаль яклау органнарыннан йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

балага яшь ярым булганчы социаль яклау органнарыннан түләнә торган бала карауга бәйле айлык пособие күләме турында, социаль яклау органнарыннан;

чакырылыш буенча хәрби хезмәт үти торган хәрби хезмәткәрнең баласына ай саен түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен компенсация күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

читләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими рәвештә мохтаҗ 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә яшь ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр (шул исәптән субсидияләр-ташламалар) күләме турында – социаль яклау органнарыннан;

торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсацияләр күләме турында – социаль яклау органнарыннан.

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарыннан.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган белешмәләр.

3.4.2. Айлык пособиене билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, – вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында – җирле үзидарә органнарына;

үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкара торган опекуннарга (попечительләргә) түләнә торган бүләк күләме турында – җирле үзидарә органнарына;

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләр күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

йөклелекнең башлангыч чорында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарына;

яшь ярымга җиткәнче бала тәрбияләгән өчен айлык пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) зат тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында, – вәкаләтле органга;

Россия ЭЭМ тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында, – Россия Эчке эшләр министрлыгына.

эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре турында – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнарына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.5. Айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече алынган, 3.4.1 пунктта күрсәтелгән белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә, шулай ук гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә

ашыра:

гариза бирүченең законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештә карар проекты рәсмиләштерә;

айлык түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе документларны караганнан соң айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карарга электрон цифрлы имза куя һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече гариза бирүче күрсәткән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп) гариза бирүчегә айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар Үзәк бүлеге белгеченә җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.7. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын яңадан рәсмиләштерә;

айлык түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан

рәсмиләштерелгән карар проектын электрон формада имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хата төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза салу өчен юлланган айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән электрон рәвешле карар проекты.

3.7.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карарга электрон цифрлы имза куя һәм аны Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган, яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.7.3. Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча, электрон почта адресы аша, телефонга смс-хәбәр рәвешендә), айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар Үзәк бүлеге белгеченә җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Үзәк бүлегендәге белгечләрнең Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм белгечләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе җаклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк белгече, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлеге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган белгечләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе

норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тарту очрагында;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи заты (учреждение белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәткәре (учреждение белгече), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение) җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение хезмәткәренең) гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение белгече булган материалларны прокуратура

органнарына кичекмәстән җибәрә.

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлегенә

______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ___
_________ 20__ ел.

Мин, ____________________________________________________________,
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адресы:____________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкиленең индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп, почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Гариза бирүченең хосусый шәхси счет номеры ____________________
_____________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес:
_____________________________________________________________________
(почта индексы, гариза бирүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләвегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Гариза бирүченең гаилә составы:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәк-лесен билгеләргә <*> |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |
| 7 | | | | |

--------------------------------

<*> үзләренә карата дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар күрсәтелә

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы хакында раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

______________________________________________________________

(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгәнмен, ата-ана хокукларында чикләнмәгән

______________ ______________________________

(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең имзасы, тулы имзасы)

Билгеләнгән пособиене әлеге счетка күчерү юлы белән башкаруыгызны сорыйм

______________________________________________________________________________

(гариза бирүче йә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштырылдым

______________________________________________

(гариза бирүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүне кире кагу турында), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында, риза:

әлеге почта адресы буенча язма формада ______________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп __________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча _____________________________

(электрон почта адресы)

Эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан минем файдага түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында Россия Федерациясе Пенсия фондында социаль ярдәм чаралары билгеләү буенча мөрәҗәгать итү аеннан алдагы соңгы 6 ай һәм 12 ай өчен булган белешмәләр нигезендә айлык пособие билгеләүгә, шул исәптән яңа чорга автомат рәвештә билгеләүгә, риза.

___________________________________

(гариза бирүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Гариза бирүче:

______________________________________ _______ «__» _____ 20__ ел.

Гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче мәнфәгатьләрендә эшли торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________ ___________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________

Өзү линиясе

Язу-белдерү

Гариза бирүченең теркәлү номеры_________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте __________ _________ ______________ ________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Мөрәҗәгать номеры | Гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре | Сәбәпләре күрсәтелмәгән мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ___ номерлы бүлегенә
_____________________________________________
_____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләү (бирү) турында
карар

№ ________ «___» ____________ 20__ ел.

Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме _________________________
_____________________________________________________________________

Гариза бирүченең адресы: ______________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләргә (бирергә)
Түләү вакыты: __________ башлап _____________кадәр

Түләү ысулы: _____________________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___номерлы бүлеге җитәкчесе
_______________________________
_______________________________ _____________________ ___________
муниципаль районда (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)
мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы бүлеге белгече
_______________________________ _____________________ ___________
муниципаль районында (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
почта адресы буенча язма формада____________________

телефонга смс-хәбәр ______________________________,
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________
(электрон почта адресы)

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы бүлегенә
______________________________
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында карар

№______ «___» ____________ 20__ ел.

Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________
______________________________
Гариза бирүченең адресы: ______________________________
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга

Баш тарту сәбәбе: ______________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___номерлы бүлеге җитәкчесе
______________________________
______________________________ ______________________________ __________
муниципаль районында (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече
______________________________ ______________________________ __________
муниципаль районында (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
почта адресы буенча язма формада____________________
телефонга смс-хәбәр ______________________________,

(телефон номеры)

электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ________________________________________
(электрон почта адресы)

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ ___ номерлы бүлегенә

______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин,______________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
түбәндәге адрес буенча яшим: ________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең шәхесен раслаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы,
_____________________________________________________________________,
документны биргән органның атамасы)
техник хатаны төзәтүегез турында сорыйм ______________________________
_____________________________________________________________________,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турындагы карарда җибәрелгән _________________________________________________.
(карар реквизитлары, бирелү датасы)
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында яңадан рәсмиләштерелгән карарны алуга риза

_____________________________________________________________________
(почта адресына язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп)
«__» _________ 20__ ел. ___________________ ___________________________
(гариза бирүченең имзасы) (тулы имза)

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |